ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.12.2020 г. Заинск № 589

**"2017-2021 елларга Зәй муниципаль районының экологик куркынычсызлыгы программасын раслау турында" 2016 елның 27 декабрендәге 3006 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында"**

Әйләнә-тирә мохитне пычратуга каршы юнәлдерелгән чараларның нәтиҗәлелеген арттыру, хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең тирә-юньгә тискәре йогынтысын кисәтә торган чаралар комплексы уздыру максатларында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендәге 3006 номерлы карары белән расланган 2017-2021 елларга экологик куркынычсызлык программасына (алга таба - программа) үзгәрешләр кертергә һәм аны кушымталар нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э.Галиев**

И.В. Гобәйдулина
(85558)3-37-47

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 22.12.
589 номерлы карарына
1 кушымта

**«2017 - 2021 елларга Зәй муниципаль районының экологик иминлеге программасы» паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2017 - 2021 елларга Зәй муниципаль районының экологик иминлеге программасы» |
| Программаны эшләү өчен нигезләр | «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон<br>"2020 елның 12 ноябрендәге 1819 номерлы карар нигезендә үзгәрешләрне исәпкә алып, 2012-2020 елларга "Әйләнә-тирә мохитне саклау" Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 15 апрелендәге 326 номерлы карары (2016 елның 13 августындагы ред.)<br>"2014 - 2021 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигый ресурсларын яңадан торгызу һәм файдалану" дәүләт программасын раслау турында" 2013 елның 28 декабрендәге 1083 номерлы ТР Министрлар Кабинеты карарына кертелгән үзгәрешләр белән «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 28 декабрендәге 1083 номерлы карары |
| Муниципаль заказчы (координатор) | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның максаты һәм бурычлары | **Төп максатлар:**<br>- экологик куркынычсызлык дәрәҗәсен күтәрү һәм табигать системаларын саклау<br>- тотрыклы үсешнең һәм халыкның социаль-икътисадый якланганлыгының кирәкле шарты буларак, ресурслардан рациональ һәм экологик куркынычсыз файдалану<br>- Зәй муниципаль районы халкының тормыш сыйфатын |

| | |
|---|---|
| | һәм сәламәтлеген яхшырту өчен кирәкле шартлар буларак, әйләнә-тирә мохитнең уңай торышын тәэмин итү<br>**Төп бурычлар**:<br>•Зәй муниципаль районы территориясендә атмосфера һавасының сыйфатын яхшырту.<br>•Зәй муниципаль районы территориясендә өске сулыкларның сыйфатын яхшырту.<br>•Табигать комплексларын, шул исәптән урманнарны яңадан утырту һәм үсемлекләр, хайваннар дөньясының биологик төрлелеген саклау һәм торгызу.<br>• Халыкның сәламәтлеге торышын яхшырту, авыруларны киметү.<br>Калдыкларны эшкәртү һәм үтилләштерү системасын кертү.<br>Зәй муниципаль районы территориясендә әйләнә-тирә мохит сыйфатын җайга салу.<br>Территорияне комплекслы бәяләүне тәэмин итү, экологик яктан имин булмаган зоналарны ачыклау, экологик иминлек өлкәсендә мәгълүмат ресурсларын булдыру һәм аларга ярдәм итү.<br>Халыкның экологик культурасы системасын, гражданлык үзаңы дәрәҗәсен һәм әйләнә-тирә мохит сыйфатын тәэмин итү өлкәсендә активлыгын үстерү |
| Программаны гамәлгә ашыруның сроклары һәм этаплары | 2017 - 2021 еллар |
| Ярдәмче программаларның исемлеге | Программа экологик һәм икътисадый вәзгыятькә бәйле рәвештә даими төзәтелә торган конкрет ярдәмче программалар системасы аша гамәлгә ашырыла:<br>1. Техноген йөкләнешләрне киметү буенча табигатьне саклау чараларын гамәлгә ашыру чаралары:<br>- атмосфера һавасын савыктыру һәм саклау чаралары;<br>2. Су объектларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау чаралары:<br>- халыкны чиста эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чаралары;<br>- суүткәргеч, канализация челтәрләрен һәм корылмаларны киңәйтү, реконструкцияләү һәм төзү чаралары;<br>- сулыкларны төзекләндерү, ландшафтларны торгызу чаралары.<br>3. Җир ресурсларыннан, үсемлекләр дөньясыннан рациональ файдалану һәм аларны саклау чаралары:<br>- җитештерү һәм куллану калдыкларын үтилләштерү, җыю, күмү чаралары;<br>- җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны |

| | |
|---|---|
| | саклау чаралары;<br>- үсемлекләр дөньясын саклау чаралары.<br>4. Халыкны савыктыруга юнәлдерелгән чаралар;<br>5. Халыкка экологик яктан белем һәм тәрбия бирү |
| Елларга бүлеп һәм чыганакларны күрсәтеп, финанслау күләмнәре | Муниципаль программаны финанслауның гомуми күләме 25670,4 мең сум тәшкил итә, шул исәптән елларга бүлгәндә:<br>2017 ел-7902,0 мең сум;<br>2018 ел-7427,8 мең сум;<br>2019 ел-4533,8 мең сум;<br>2020 ел-3418,8 мең сум;<br>2021 ел-2388,0 мең сум.<br>Программаны финанслау Федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, Зәй муниципаль районы бюджетыннан, законнар нигезендә бюджеттан тыш акчалардан шушы максатларга бүлеп бирелә торган чыганаклар булганда һәм чаралар чикләрендә гамәлгә ашырыла. Программаны бюджет финанславы күләме һәм структурасы барлык дәрәҗәдәге бюджетларның расланган параметрлары нигезендә һәм программа чараларын фактта үтәүне исәпкә алып ел саен төгәлләштерелергә тиеш. |
| Елларга бүлеп, программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре белән программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелгән соңгы нәтиҗәләр | Программаның төп чараларын гамәлгә ашыру, аерым алганда, мөмкинлек бирәчәк:<br>- атмосфера һавасына техноген йөкләнешне киметергә;<br>- грунт суларының һәм туфракның пычрануын булдырмаска;<br>- предприятиеләрнең аз калдыклы, ресурсларны саклый торган технологияләргә күчүе, җитештерү һәм куллану калдыкларын, үсемлек калдыкларын урнаштыру өчен шартлар тудыруы исәбенә сәнәгать калдыклары барлыкка килүне киметергә;<br>- Зәй шәһәренең һәм авыл җирлекләренең урамнарын һәм скверларын яшелләндерергә һәм төзекләндерү чараларын гамәлгә ашырырга;<br>- әйләнә-тирә мохитне пычратуны кисәтү буенча кабул ителә торган чараларның оперативлыгын һәм нәтиҗәлелеген арттырырга;<br>- халык сәламәтлегенә техноген йогынты ясау факторларын ачыкларга;<br>- халыкка экологик культура, белем бирү һәм мәгълүматлы итү дәрәҗәсен арттырырга;<br>- әйләнә-тирә мохитнең торышын яхшыртырга, узган һәм агымдагы хуҗалык эшчәнлегенә бәйле экологик куркынычны киметергә; |

## 1. **Программа методлары белән проблеманы чишүнең башлангыч торышын анализлау һәм аны хәл итү кирәклеген нигезләү**

Татарстан Республикасында җитештерү көчләренең үсеше матди һәм мәдәни байлыкның үсүенә генә түгел, ә әйләнә-тирә мохитне тагын да интенсив пычратуга һәм экологик тигезлекне бозуга да китерде. Үсә барган эксплуатация һәм табигать ресурсларын эшкәртү белән калдыклар күләме дә арта, алар табигый мохиткә кире кайта. Шуңа күрә хәзерге шартларда җәмгыять белән табигать арасындагы үзара мөнәсәбәтләр проблемасын хәл итү беренчел әһәмияткә ия.

Пычрату чыганаклары булып торак-коммуналь предприятиеләрнең, предприятиеләр һәм оешмаларның чистартылмаган коммуналь-көнкүреш һәм сәнәгать калдыклары, агып ята торган нефть продуктлары һәм чүп-чар тора. Канализацияле чистарту корылмалары сулыкларга чыгарыла торган суларны чистартуның заманча таләпләренә җавап бирми торган технологияләрне кулланалар. Җитештерү һәм куллану калдыклары әйләнә-тирә мохиткә һәм халыкның сәламәтлегенә тискәре йогынты ясый торган җитди фактор булып тора, шул ук вакытта алар - икенчел матди ресурслар чыганагы да.

Зәй муниципаль районында елына 660 мең тоннага якын калдыклар барлыкка килә. Болар - сәнәгать, төзелеш һәм биологик калдыклар, шулай ук каты көнкүреш калдыклары һәм юынтык сулар.

Сәнәгать калдыклары, каты көнкүреш калдыклары кебек үк, химик составы буенча төрле. Җир асты суларына үтеп керә ала торган һәм туфрак-үсемлек капламына тискәре йогынты ясый торган күп кенә агулы матдәләрнең югары концентрацияле сыек җитештерү калдыклары һәм юынтык сулар аеруча зур куркыныч тудыра. Калдыкларның төп массасы каты көнкүреш калдыкларының оешкан чүплекләренә чыгарыла, анда әйләнә-тирә мохит өчен яңа куркыныч матдәләр барлыкка килергә мөмкин.

Чүплектәге калдыкларның атмосферадагы явым-төшемнәр белән тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килә торган фильтрат аеруча куркыныч санала. Фильтратта органик һәм минераль матдәләр таркалуның күп санлы компонентлары бар. Участокның гидрогеологик төзелешенә бәйле рәвештә, чүплекләрдә калдыклар күмелгәннән соң фильтрат ясалу 1 елдан 25 елга кадәр бара. Фильтрат белән пычрануга аеруча актив су алмашы зоналары, беренче чиратта грунт сулары дучар була. Чүплек атмосфераны да, гидросфераны да агулый, үсемлек капламын һәлак итә, уңайсыз яшәү тирәлеге тудыра. Көнкүрештән агып чыккан юынтык сулар да куркыныч: аларның әйләнә-тирә табигать мохитенә тискәре йогынтысын киметү барлык урбанизацияле территорияләрнең мөһим проблемасы булып тора. Куркыныч бу очракта яшәү тирәлегенең бактерияләр белән пычрануы һәм эпидемияләр кабынып китү ихтималы белән бәйле.

Сәнәгать һәм көнкүреш калдыклары барлыкка килү, куллану, зарарсызландыру, саклау һәм күмү проблемаларына традицион якын килү муниципаль район халкының сәламәтлегенә зыян китерә торган, экологик

тигезләнешне начарайта торган, территориянең пычрануы белән характерлана торган вәзгыятькә китерде.

Программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә шәһәрнең сәнәгать предприятиеләре әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясауны киметәчәк.

Әйләнә-тирә мохиткә тискәре антропоген йөкләнешне киметү тирәлек торышында сыйфатлы уңай үзгәрешләргә һәм Зәй муниципаль районы халкының экологик иминлеген арттыруга китерәчәк.

Шәһәр халкының яшәү шартларын яхшырту, экологик мәгълүматлылык дәрәҗәсен һәм грамоталылыгын арттыру шәһәрнең тотрыклы үсеше өчен өстәмә стимул булдырырга мөмкинлек бирәчәк.

## 2. Төп максатлар һәм бурычлар, гамәлгә ашыру этаплары

Программаның төп максатлары:

-әйләнә-тирә мохиткә чыгарылган зарарлы матдәләрне бетерүгә юнәлдерелгән чараларның нәтиҗәлелеген күтәрү;

-әйләнә-тирә мохитнең сыйфатында тискәре үзгәрешләргә китерә торган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең начар йогынтысын кисәтә торган чаралар комплексы үткәрү.

Программаның төп бурычлары:

- шәһәр предприятиеләре тарафыннан атмосферага зарарлы матдәләр чыгаруның билгеләнгән нормаларын үтәү;
- шәһәр предприятиеләре тарафыннан су объектларына зарарлы матдәләр агызуны киметү;
- су объектларыннан рациональ файдалану һәм аларны саклау;
- җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау;
- шәһәрдә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүне оптимальләштерү;
- шәһәрнең яшел фондын саклап калу һәм үстерү;
- шәһәр халкының уңайлы тормыш шартларын тәэмин итү;
- халыкны экологик агарту.

Программа 2017 - 2021 елларда гамәлгә ашырыла.

Программаны гамәлгә ашыру сроклары программа чараларын тәэмин итүнең ресурс мөмкинлекләрен исәпкә ала. Бу чор әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә беренче чираттагы бурычларны хәл итәргә һәм, Зәй муниципаль районының әйләнә-тирә мохиткә һәм халык сәламәтлегенә тискәре йогынтыны булдырмау максатларында, инфраструктураны тотрыклы үстерү өчен нигез булдырырга мөмкинлек бирә.

## 3. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаның заказчысы булып Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты тора.

Программаны гамәлгә ашыру процессы белән идарә итү Зәй муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләнгән. Программаның үтәлешен координацияләү Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләнгән. Программаны гамәлгә

ашыру механизмы барлык программада катнашучыларның вәкаләтләрен һәм җаваплылыгын төгәл бүлешүенә нигезләнә.

## 4. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслау Федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, Зәй муниципаль районы бюджетыннан, законнар нигезендә бюджеттан тыш акчалардан шушы максатларга бүлеп бирелә торган чыганаклар булганда һәм бирелгән средстволар чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Программаны бюджеттан финанслау күләме һәм структурасы барлык дәрәҗәдәге бюджетларның расланган параметрлары нигезендә һәм программа чараларын фактта үтәүне исәпкә алып ел саен төгәлләштерелергә тиеш.

Программа чаралары буенча эшләрнең бәясе эшләрне башкару сметалары нигезендә билгеләнә.

## 5. Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү

Программа чараларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген социаль, икътисадый һәм экологик аспектларда карарга кирәк.

Икътисадый нәтиҗәгә ирешеләчәк:

-су һәм һава киңлекләренә нормадан тыш зарарлы матдәләр чыгаруны, сәнәгать һәм көнкүреш калдыкларын үтилләштерүнең заманча ысулларын кертү өчен түләүгә бәйле продукция җитештергәндә предприятиеләр чыгымнарын киметү аша;

-җитештерү һәм көнкүрештән чыккан җыентык суларның тирә-юньгә тискәре йогынтысын киметү аша.

Экологик нәтиҗәгә ирешеләчәк:

-әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметү, аны бетерү;

-Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан торак пунктларның санитар торышын яхшырту;

-техноген һәм табигатьтә гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу ихтималын киметү аша.

Социаль нәтиҗәгә ирешеләчәк:

- муниципаль район халкының сәламәтлеген яхшырту;

-әйләнә-тирә мохитнең торышы турында халыкны тагын да мәгълүматлы итү;

-программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре белән халыкның кызыксынучанлыгын арттыру;

-гражданнарның әйләнә-тирә мохит торышы турында белемнәргә тотрыклы ия булуына ихтыяҗларын гамәлгә ашыру юллары аша.

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 22.12.
589 номерлы карарына
2 кушымта

6. «2017-2021 елларга Зәй муниципаль районының экологик иминлек программасы»
төп чаралар планы һәм көтелгән нәтиҗәләр

| № п/п | Чаралар | Башкаручы оешма | Баш кару срок лары | Финанслауның күздә тотылган чыганаклары | Финанс чыгымнарына күздә тотылган ихтыяҗ (мең сумнарда) | | | | | | Көтелә торган нәтиҗәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | всего | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 1. Техноген йөкләнешне киметү буенча табигатьне саклау чараларын гамәлгә ашыру<br>1.1. Атмосфера һавасын савыктыру һәм саклау гамәлләре | | | | | | | | | | | |
| 1.1.1 | 2-12 нче номерлы энергетик пар калориферларының регенератив һава җылыткычлары өслекләрен юдыру | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 1000,0 | 200,0 | 200,0 | 200,0 | 200,0 | 200,0 | Зарарлы матдәләр чыгаруны киметү:елына NOx -1,03 т, SO2-15,84 т, CO-2,0 т, корым- 0,335 т , маз.көле - 0,043 т. Энергия ресурсларын экономияләүне- 390 тут |
| 1.1.2 | Атмосферага газлар белән бергә чыга торган зарарлы матдәләрне инструментлар ярдәмендә үлчәү | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 334,7 | 8,9 | 8,9 | 8,9 | 154,0 | 154,0 | Зарарлы матдәләр чыгу сәбәпләрен вакытында ачыклап хәл итү |
| 1.1.3 | Санитар-саклау зонасы (СЗЗ) чигендә, предприятие йогынтысы зонасындагы шәһәр территориясендә атмосф.һавасы торышына контроль (инструментлар ярдәмендә углеводородлар күләмен C12-C19) | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 48,9 | 16,3 | 16,3 | 16,3 | | | Атмосферага зарарлы матдәләр чыгу сәбәпләрен вакытында ачыклап хәл итү |
| 1.1.4 | Санитар-саклау зонасы (СЗЗ) чигендә атмосфера һавасы торышына лаборатор тикшерү | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 501,9 | 62,9 | 62,9 | 62,9 | 156,6 | 156,6 | Зарарлы матдәләр чыгу сәбәпләрен вакытында ачыклап хәл итү |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.1.5 | «Циклон» тузан тоткарлау җайланмасын көйләү, аның нәтиҗәлеле эшләвен тикшерү | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 3,0 | 1,0 | 1,0 | 1,0 | | | Атмосферага чистартмыйча зарарлы матдәләр чыгаруны булдырмау. УОГ нәтиҗәле эшләвен ачыклау |
| 1.1.6 | КВО фильтрларын һәм полимерлаштыру камераларын алыштыру. ХВО фильтрларында һәм полимерлаштыру камераларында тыгызлыгы 50 кг/м3 булган минераллы плитәләр куллану | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ҖЧҖ филиалы | 2017-2021 | Предприятиенең үз средстволары | 14400,0 | 2800,0 | 2900,0 | 2900,0 | 2900,0 | 2900,0 | Атмосфераның потенциаль пычранган зонасын булдырмау |
| 1.1.7 | Санитар-саклау зонасы (СЗЗ) чигендә атмосфера һавасын һәм тавыш катылыгын контрольдә тоту | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ҖЧҖ филиалы | 2017-2021 | Предприятиенең үз средстволары | 300,0 | 60,0 | 60,0 | 60,0 | 60,0 | 60,0 | Нормадан тыш калдыклар чыгаруны булдырмау |
| 1.1.8 | ИЗА чыганакларыннан атмосферага чыгарылган зарарлы матдәләр микъдарен инструмент кулланып үлчәү | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ҖЧҖ филиалы | 2017-2021 | Предприятиенең үз средстволары | 150,0 | | | | | 150,0 | Табигатьне саклау законнарын үтәү |
| 1.1.9 | Санитар-саклау зонасы (СЗЗ) чигендә атмосфера һавасының торышын күзәтү | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ҖЧҖ филиалы | 2017-2021 | Предприятиенең үз средстволары | 60,0 | | | | | 60,0 | Табигатьне саклау законнарын үтәү |
| 1.1.10 | Зарарлы матдәләр чыккан урыннарда ПДВ нормалары үтәлешенә атмосфераны тикшерү | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ҖЧҖ филиалы | 2017-2021 | Предприятиенең үз средстволары | 560,0 | 140,0 | 140,0 | 140,0 | 140,0 | | Нормадан тыш калдыклар чыгаруны булдырмау |
| 1.1.11 | ПДВ проектын эшләү | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ҖЧҖ филиалы | 2017-2021 | Предприятиенең үз средстволары | 150,00 | | | | 150,00 | | Нормадан тыш калдыклар чыгаруны булдырмау |
| 1.1.12 | Санитар-саклау зонасы (СЗЗ) проектын эшләү | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017-2021 | Предприятиенең үз средстволары | 120,00 | 120,00 | | | | | Нормадан тыш калдыклар чыгаруны булдырмау |
| 1.1.13 | Вагранкадан чыккан газларны яндырып бетерү системасы фильтрларын алыштыру | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017-2021 | Предприятиенең үз средстволары | 45000,0 | 9000,00 | 9000,00 | 9000,0 | 9000,0 | 9000,0 | Табигатьне саклау законнарын үтәү |
| 1.1.14 | Газлардан чистарту җайланмасы (ГОУ) куллануга контроль | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 15,0 | - | - | - | - | 15,0 | Атмосферага зарарлы матдәләр чыгаруны киметү |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.1.15 | Рөхсәт ителгән иң чик зарарлы матдәләр чыгару (ПДВ проекты) проектын эшләү | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 150,0 | | | | | 150,0 | Табигатьне саклау законнарын үтәү |
| 1.1.16 | СЗЗда һәм фильтрация кырларында атмосфера һавасы торышына химик-аналитик контроль | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 – 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 89,0 | 17,0 | 17,0 | 18,0 | 18,0 | 19,0 | Калдыклар чыгаруны киметү: шикәр тузаны, агач тузаны |
| 1.1.17 | Газларны чистарту җайланмаларына (ГОУ) агымдагы ремонт | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 – 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 50,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | Калдыклар чыгаруны киметү: шикәр тузаны, агач тузаны |
| 1.1.18 | Газларны чистарту җайланмалары (ГОУ) нәтиҗәле эшчәнлегенә контроль | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 – 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 50,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | Калдыклар чыгаруны киметү: шикәр тузаны, агач тузаны |
| 1.1.19 | ПДВ нормалары үтәлешенә контроль | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 – 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 200,0 | 40,0 | 40,0 | 40,0 | 40,0 | 40,0 | Калдыклар чыгаруны киметү: шикәр тузаны, агач тузаны |
| 1.1.20 | Автомобильләрдән чыккан газларның токсиклыгын (төтенләвен) тикшереп тору | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 – 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 30,0 | 6,0 | 6,0 | 6,0 | 6,0 | 6,0 | Атмосфера һавасының торышын тикшереп тору |
| 1.1.21 | Зарарлы матдәләр чыгаруның нормативлары үтәлешенә контроль | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 – 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 100,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | Атмосфера һавасының торышын тикшереп тору |
| 1.1.22 | ПДВ нормативлары үтәлешенә һәм газлардан чистарту җайланмаларының нәтиҗәле эшләвенә лаборатор тикшерүләр үткәрү | "Аккурайд Уилз Руссиа" ҖЧҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 520,0 | 100,0 | 105,0 | 105,0 | 105,0 | 105,0 | ГОТ һәм ПБ Калдыклар чыгаруга контрольне көчәйтү |
| 1.1.23 | ПДВ проектын эшләү һәм Роспотребнадзор белән килештерү, зарарлы матдәләр чыгаруга рөхсәт алу | "Аккурайд Уилз Руссиа" ҖЧҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 140,0 | | | | 140,0 | | ГОТ һәм ПБ Табигатьне саклау законнарын үтәү |
| 1.1.24 | Санитар-яклау зонасында тикшерүләр үткәрү | "Аккурайд Уилз Руссиа" ҖЧҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 125,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 | ГОТ һәм ПБ Калдыклар чыгаруга контрольне көчәйтү |

**2. Су объектларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау чаралары**

**2.1. Халыкны чиста эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чаралары**

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.1.1 | Судан файдалану урыннарында Дала Зәе елгасына һәм Зәй сусаклагычына мониторинг | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 999,4 | | | | 499,7 | 499,7 | Дала Зәе елгасына агып төшүче суларның йогынтысын билгеләү һәм тикшереп тору максатында мониторинг алып бару |
| 2.1.2 | Бөгелде елгасына агып төшә торган җитештерү, яңгыр суларына һәм су объектына аналитик контроль | "Аккурайд Уилз Руссиа" ҖЧҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 300,0 | 60,0 | 35,0 | 35,0 | 35,0 | 135,0 | Ташлауларга контрольне көчәйтү |
| 2.1.3 | Поповкада чишмәне чистарту | Поповка А/Җ башкарма комитеты | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 300,0 | 300,0 | | | | | Халыкны эчә торган су белән тәэмин итү |
| **2.2. Суүткәргеч, канализация челтәрләрен һәм корылмаларын киңәйтү, реконструкцияләү һәм төзү** | | | | | | | | | | | |
| 2.2.1 | 2-12 нче энергоблокларда май суыткычларны һәм тукландыру насосларын опрессовкалау | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 250,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Сулыкка елына 0,2 тоннага кадәр май эләгүне булдырмау |
| 2.2.2 | КТЦ-1,2 котельный һәм турбина бүлекләренең приямкаларын һәм каналларын ремонтлау һәм чистарту | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 500,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | Агызыла торган суларга елына 0,4 тоннага кадәр май чыгаруны булдырмау |
| 2.2.3 | Биологик тест методы белән кулланышта булып, чистартылган суларга токсинлылыкка анализ үткәрү | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 227,9 | | | 227,9 | | | Пычрата торган матдәләр чыгу сәбәпләрен вакытында бетерү |
| 2.2.4 | Химик һәм токсинлылык күрсәткечләрен белеп тору өчен суларны лаборатор тикшерүләр | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 1003,8 | | | | 501,9 | 501,9 | Пычрата торган матдәләр чыгу сәбәпләрен вакытында бетерү |
| 2.2.5 | Куллануга кире кайтарылган суларны микрибиологик һәм паразитологик тикшерүләр (агынты суларга җитештерү контроле) | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 245,8 | | | | 122,9 | 122,9 | Пычрата торган матдәләр чыгу сәбәпләрен вакытында бетерү |
| 2.2.6 | Фильтрлау кырларына сәнәгать сулары агып чыга торган басымлы торба үткәргечләрне алыштыру | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 210,0 | 45,0 | 50,0 | 55,0 | 40,0 | 20,0 | Аварияләрсез эшләүдә ышанычлылыкны арттыру |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.2.7 | Буа - шартлы чиста су суыткычы төзү | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 14,000 | 5,0 | 5,0 | 4,0 | | | Һавага чыга торган матдәләрне киметү |
| 2.2.8 | Транспортлау-юу суларын радиаль тондыргыч төзү | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 82,0 | 20,0 | 22,0 | 20,0 | 20,0 | | Һавага чыга торган матдәләрне киметү |
| 2.2.9 | Фильтрлау кырларын ремонтлау, валларны ныгыту | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 2320,0 | 450,0 | 450,0 | 470,0 | 470,0 | 480,0 | Аварияләрсез эшләүдә ышанычлылыкны арттыру |
| 2.2.10 | Җир асты резервуарын чистартып, артезиан скважиналарга агымдагы ремонт үткәрү | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 225,0 | 45,0 | 45,0 | 45,0 | 45,0 | 45,0 | Аварияләрсез эшләүдә ышанычлылыкны арттыру |
| 2.2.11 | Фильтрация кырларының бүлү җайланмаларын ремонтлау (Д=325 мм) | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 215,0 | 40,0 | 40,0 | 45,0 | 45,0 | 45,0 | Авариясез эшләүдә ышанычлылыкны арттыру |
| 2.2.12 | Агынты һәм табигый сларга химик-аналитик контроль | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 965,0 | 190,0 | 190,0 | 195,0 | 195,0 | 195,0 | Бөгелде елгасына мониторинг |
| 2.2.13 | Артезиан суына химик-аналитик контроль | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 334,0 | 65,0 | 65,0 | 68,0 | 68,0 | 68,0 | Скважиналардагы суның сыйфатына мониторинг |
| 2.2.14 | Махсус автомойкада автотранспорт юу | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 215,0 | 40,0 | 40,0 | 45,0 | 45,0 | 45,0 | Нефть продуктлары ташлауны булдырмау |
| 2.2.15 | НДС проектын эшләү | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 200,0 | 200,0 | | | | | Табигатьне саклау законнарын үтәү |
| **2.3. Эрозиягә каршы чаралар, сулыкларны сәламәтләндерү һәм төзекләндерү, ландшафтларны торгызу** | | | | | | | | | | | |
| 2.3.1 | Су объектын гидрохимик күзәтүләр,<br>Дала Зәе елгасы, су ташлана торган җирдән 500м. югары һәм түбәндә | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017 - 2021 | Собств. средства предприятия | 207,6 | 69,2 | 69,2 | 69,2 | | | Предприятиенең Дала Зәе елгасына юынтык су агызуның йогынтысын билгеләү һәм контрольдә тоту максаты белән локаль дәрәҗәдә мониторинг алып бару |
| 2.3.2 | Җир асты суларын җыю участогын төзекләндерү | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 45,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 | | | Грунт суларының пычрануын булдырмау |
| 2.3.3 | Табигый һәм агынты суларны лаборатор тикшеренүләр (житештерү контроле) | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 241,7 | | | 241,7 | | | Пычрата торган матдәләр ташлануның сәбәпләрен вакытында бетерү |
| 2.3.4 | Юынтык суларны санитар-микробиологик тикшерү | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 52,8 | 17,6 | 17,6 | 17,6 | | | Пычрату матдәләре чыгуның сәбәпләрен вакытында бетерү |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.3.5 | Яр буе насос станцияләрендә балык саклау җайланмаларына техник хезмәт күрсәтү | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 1306,0 | | | | 1306,0 | | Су җыйганда Зәй сусаклагычына тискәре йогынтыны киметү |
| 2.3.6 | 2,3 номерлы яр буе насос станцияләрендә балык саклау җайланмаларының нәтиҗәлелеген бәяләү | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 1762,5 | | | 1762,5 | | | Дала Зәе елгасы ихтиофаунасына агып төшүче пычрак суларның урынында тискәре йогынтысын билгеләү |
| 2.3.7 | Яңгыр сулары канализациясен механик кисәкчәләрдән чистарту | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ҖЧҖ филиалы | 2017-2021 | Предприятиенең үз средстволары | 160,0 | 40,0 | 40,0 | 40,0 | 40,0 | | Бөгелде елгасында пычрату калдыкларын киметү |
| 2.3.8 | Хуҗалык-фекалия суларының һәм яңгыр суларының торышын тикшереп тору | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ҖЧҖ филиалы | 2017-2021 | Предприятиенең үз средстволары | 200,0 | 50;0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | | Бөгелде инешендә пычрану зонасын булдырмау |
| 2.3.9 | Яңгыр сулары канализациясендәге суларны прозводствода куллану | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ҖЧҖ филиалы | 2017-2021 | Предприятиенең үз средстволары | 80,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | | Бөгелде инешендә пычрану зонасын булдырмау |
| 2.3.10 | Балыкларны саклау җайланмасына агымдагы ремонт үткәрү | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 125,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 | Авариясез эшләүдә ышанычлылыкны арттыру |
| 2.3.11 | Тондыргычны (отстойник) чистарту, фильтрлау кыры картларын сөрү | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 1950,0 | 390,0 | 390,0 | 390,0 | 390,0 | 390,0 | Туфрак эррозиясе булдырмау |
| 2.3.12 | Кабан Бастрыкта чишмәне төзекләндерү | Башкарма комитет | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 300,0 | | 300,0 | | | | Төзекләндерү |
| 2.3.13 | Сармаш Башта чишмәне төзекләндерү | Башкарма комитет | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 300,0 | | 300,0 | | | | Төзекләндерү |
| 2.3.14 | Гулькинда «Изгеләр чишмәсен» төзекләндерү | Башкарма комитет | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 300,0 | | 300,0 | | | | Төзекләндерү |
| 2.3.15 | Куш Елгада чишмәне төзекләндерү | Башкарма комитет | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 300,0 | | | 300,0 | | | Төзекләндерү |
| 2.3.16 | Кара Елгада чишмәне төзекләндерү | Башкарма комитет | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 400,0 | | | 400,0 | | | Төзекләндерү |
| 2.3.17 | Урсайда чишмәне төзекләндерү | Башкарма комитет | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 300,0 | | | 300,0 | | | Төзекләндерү |
| 2.3.18 | Иске Мавринда чишмәне төзекләндерү | Башкарма комитет | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 300,0 | | | | 300,0 | | Төзекләндерү |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.3.19 | Төгидә чишмәне төзекләндерү | Башкарма комитет | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 300,0 | | | | | 300,0 | Төзекләндерү |
| 2.3.20 | Багражда чишмәне төзекләндерү | Башкарма комитет | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 300,0 | | | | | 300,0 | Төзекләндерү |
| 2.3.21 | Карманда чишмәне төзекләндерү | Башкарма комитет | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 300,0 | | | | | 300,0 | Төзекләндерү |
| 2.3.22 | Бөгелде елгасының су саклау зонасы ярларын чистарту һәм ныгыту | Башкарма комитет | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 770,0 | | 470,0 | | 300,0 | | Ярларны ныгыту |
| 2.3.23 | Янгынгы каршы чара буларак Поповкада буа ярын ныгыту | Поповка авыл җирлеге башкарма комитеты | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 200,0 | | | 100,0 | 100,0 | | Ярларны ныгыту |
| 2.3.24 | Кармалка елгасының үзәнен чистарту һәм су саклау зонасы ярларын ныгыту | ЗМР Башкарма комитеты | 2017-2021 | ЗМР бюджеты | 1250,0 | 1000,0 | | | | 250,0 | Ярларны ныгыту |
| 2.3.25 | ГТСны капиталь ремонтлауның проект-смета документларын эшләү | ЗМР Башкарма комитеты | 2017-2021 | ЗМР бюджеты | 990,0 | | 990,0 | | | | Су ресурсларын саклау |
| 2.3.26 | ГТСны декларация алды тикшерүе | ЗМР Башкарма комитеты | 2017-2021 | ЗМР бюджеты | 1000,0 | | 300,0 | 300,0 | 400,0 | | Су ресурсларын саклау |
| 2.3.27 | ГТС зыянын исәпләү + иминиятләштерү | ЗМР Башкарма комитеты | 2017-2021 | ЗМР бюджеты | 1060,0 | | | 600,0 | 460,0 | | Су ресурсларын саклау |
| **3. Җир ресурсларын, үсемлекләр дөньясын рациональ файдалану һәм саклау буенча чаралар**<br>**3.1. Җитештерү һәм куллану калдыкларын утилләштерү, туплау, күмү** | | | | | | | | | | | |
| 3.1.1 | Икенчел матди ресурсларга караган калдыкларны эшкәртү һәм утилләштерүгә тапшыру | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 5630,4 | 1876,8 | 1876,8 | 1876,8 | | | Әйләнә-тирә мохиткә йөкләнеш елына 3,67 мең тоннага кимегән |
| 3.1.2 | Алга таба калдыкларны утилләштерү һәм зарарсызландыру максатларында жыю хезмәте күрсәтү | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 4715,6 | | | | 2357,8 | 2357,8 | Әйләнә-тирә мохиткә йөкләнеш елына 11,476 мең тоннага кимегән |
| 3.1.3 | Җитештерү процессының, кулланыла торган чималның һәм калдыклар белән эш итүнең үзгәрешсезлеге турында техник хисап | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ҖЧҖ филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 100,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | Җитештерү калдыкларының барлыкка килүен һәм аларның кая куелуын исәпкә алу |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.1.4 | Җитештерү калдыкларын вакытында чыгару һәм үтилләштерү | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ҖЧҖ филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 7500,0 | 1500,0 | 1500,0 | 1500,0 | 1500,0 | 1500,0 | Әйләнә-тирә мохитнең җитештерү калдыклары белән пычрануын булдырмау |
| 3.1.5 | Икенчел калдыкларны тапшыру (макулатура, резина, чүпрәк-чапрак һ. б.) | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 200,0 | 40,0 | 40,0 | 40,0 | 40,0 | 40,0 | Күмелә торган калдыкларны киметү |
| 3.1.6 | Җитештерү процессының үзгәрешсезлеге турында техник хисап | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 125,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 | Табигатьне саклау законнарын үтәү |
| 3.1.7 | Куркыныч калдыкларның паспортларын эшләү | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 210,0 | 110,0 | 100,0 | | | | Табигатьне саклау законнарын үтәү |
| 3.1.8 | Карьерларны рекультивацияләү | ЗМР Башкарма комитеты | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 1131,5 | | 1131,5 | | | | Туфракның уңдырышлы катламын торгызу |
| 3.1.9 | Карьерларны проектлау | ЗМР Башкарма комитеты | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 1145,0 | 845,0 | 300,0 | | | | |
| 3.1.10 | Санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү | ЗМР Башкарма комитеты | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 2750,0 | 350,0 | 600,0 | 500,0 | 700,0 | 600,0 | Туфракның уңдырышлы катламын торгызу |
| 3.1.11 | Калдыкларны җыю, бетерү, үтилләштерү, зарарсызландыру системасын оештыру (контейнер мәйданчыклары) | ЗМР Башкарма комитеты | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 1450,0 | 630,0 | 670,0 | 150,0 | | | |
| 3.1.12 | Икенчел файдаланылырга тиешле калдыкларны аеру максаты белән калдыкларны селектив җыюны оештыру (батарейкалар өчен контейнерлар) | ЗМР Башкарма комитеты | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 100,0 | | | 100,0 | | | |
| **3.2. Җир ресурсларыннан рациональ файдалану һәм саклау** | | | | | | | | | | | |
| 3.2.1 | Калдыклар белән эш итүдә җитештерү контроле тәртибен эшләү | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017, 2020 | Предприятиенең үз средстволары | 140,0 | 70,0 | | | 70,0 | | Табигатьне саклау законнарын үтәү |
| **3.3. Яшелләндерү һәм үсемлекләр дөньясын саклау** | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.3.1 | Предприятие территориясен яшелләндерү һәм төзекләндерү эшләре | «Генерацияләү компаниясе» ААҖ Зәй ГРЭСы филиалы | 2017, 2020 | Предприятиенең үз средстволары | 175,8 | | | | 87,9 | 87,9 | 3 га жирне деградацияләүдән чыгару |
| 3.3.2 | 100 данәдән артык агач утырту, Перцовкага таба юл буйлап агачлар утырту. | Зәй шәһәренең «ТЕХНО заводы» ҖЧҖ филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 60,0 | | | | | 60,0 | Әйләнә-тирәлекнең пычрануын киметү |
| 3.3.3 | Предприятие территориясен яшелләндерү | «Зәй шикәре» ААҖ | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 50,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | |
| 3.3.4 | Яшел үсентеләр сатып алу һәм утырту, агачларны санитар кисү. | ЗМР Башкарма комитеты | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 8616 | 3116,0 | 2000,0 | 1800,0 | 1100,0 | 600,0 | Әйләнә-тирәлекнең пычрануын киметү |
| 3.3.5 | Яшел үсентеләрне күчереп утырту өчен җиһаз сатып алу | ЗМР Башкарма комитеты | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 1450,0 | 1450,0 | | | | | |
| **4. Экологик тәрбия, белем бирү һәм агарту эшчәнлеге** | | | | | | | | | | | |
| 4.1 | Әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре буенча персоналның квалификациясен күтәрү | «Зәй ГРЭСы генерацияләү компаниясе» ААҖ филиалы | 2017 - 2021 | Предприятиенең үз средстволары | 57,0 | 15,0 | 15,0 | 13,5 | 9,0 | 4,5 | Табигатьне саклау эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру |
| 4.2 | Халыкара жир көне, Экологик белемнәр көне, Урман көненә багышланган экологик акцияләр оештыру, «Эзләнү һәм казанышлар офыклары» фәнни-гамәли конференциясе, «Чиста урман», «Сыерчык оясы " экологик акцияләре | «ТР ЗМР мәгариф идарәсе» МКУ | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 95,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 15,0 | Табигый бергәлек системасы һәм анда кешенең тоткан урыны турында тулы бер фәнни күзаллау һәм белемнәр формалаштыру |
| 4.3 | Күрсәтмә-экологик мәгълүмати материал әзерләү | «ТР ЗМР мәгариф идарәсе» МКУ | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 90,0 | 30,0 | 16,3 | 26,8 | 8,8 | 8,0 | Экологик белемнәрне күтәрү |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.4 | «Эко Зәй», «Чиста шәһәр – безнең эшебез», «Йолдызлы җыештыру», «Агач утырт!», «Яшьләр-чүпкә каршы», «Ага чишмә челтер-челтер», «оБЕРЕГай», «Шәһәр елгаларына - чиста ярлар», «Яшьтән табигать турында кайгыртыйк», «Кеше булып калыйк!" экологик акцияләре | «ТР ЗМР яшьләр эшләре идарәсе» МКУ | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 142,0 | 30,0 | 30,0 | 37,0 | 30,0 | 15,0 | Экологик белемнәрне күтәрү |
| 4.5 | Яшел дөнья синең кулларда» экологик конференциясе, «Экодулкын" I шәһәр экологик яшьләр форумы | «ТР ЗМР яшьләр эшләре идарәсе» МКУ | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 20,0 | 20,0 | | | | | |
| 4.6 | 9-11 сыйныф укучыларын профильле әзерләү буенча эш | «ТР ЗМР мәгариф идарәсе» МКУ | 2017 - 2021 | Мәгариф идарәсенең төп эшчәнлеген финанслау | чыгымнардан башка | | | | | | Алынган экологик белемнәрне конкрет эш урынында, булачак һөнәри эшчәнлектә грамоталы файдалану |
| 4.7 | Мәктәп балаларына экологик белем бирү буенча авторлык программалары конкурсы уздыру | «ТР ЗМР мәгариф идарәсе» МКУ | 2017 - 2021 | Мәгариф идарәсенең төп эшчәнлеген финанслау | чыгымнардан башка | | | | | | Укучыларны һәм укытучыларны табигатьне саклау буенча иҗтимагый эшчәнлеккә җәлеп итү |
| 4.8 | Белем бирү учреждениеләре базасында оештырылган экологик отрядларның эшчәнлеген оештыру | «ТР ЗМР мәгариф идарәсе» МКУ | 2017 - 2021 | Мәгариф идарәсенең төп эшчәнлеген финанслау | чыгымнардан башка | | | | | | Укучыларны гамәли экологик эшчәнлеккә җәлеп итү |
| 4.9 | ЭХБ лаборатор эшләре өчен (экология, химия, биология) класс комплекты | «ТР ЗМР мәгариф идарәсе» МКУ | 2017 - 2021 | ЗМР бюджеты | 111,0 | 111,0 | | | | | Төп мохитләр - һава, су һәм туфракны, шулай ук азык-төлек продуктларын экологик тикшеренүләрдә, әлеге тирәлек турында фәнни күзаллаулар кулланып, укучылар тарафыннан күрсәтмә тәҗрибәләрне мөстәкыйль уздыру |
| | **Муниципаль бюджет средстволары** | | | | **25670,4** | **7902,0** | **7427,8** | **4533,8** | **3418,8** | **2388,0** | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | **Предприятиеләрнең үз средстволары** | **97599,5** | **18240,7** | **17927,7** | **20199,3** | **21322,8** | **19909,0** | |
| | **Барысы** | **123269,9** | **26142,7** | **25355,5** | **24733,1** | **24741,6** | **22297,0** | |

Татарстан Республикасы
Зәймуниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның ___ ________
___ номерлы карарына
3 кушымта

# Акчаларны еллар һәм чыганаклар буенча бүлү таблицасы

| № п/п | Чараларның исеме | Финанслау чыганаклары | Финанс чыгымнарына күздә тотылган ихтыяж (мең сум). | | | | | | Индикаторларның күрсәткече | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барысы | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2017 ел. | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| 1 | Санкцияләнмәгән чүплекләрне юк итү | Муниципаль бюджет | 2450,0 | 350,0 | 600,0 | 500,0 | 700,0 | 700,0 | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 |
| 2 | Карьерларны рекультивацияләү | | 1131,5 | | 1131,5 | | | | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| 3 | Карьерларны проектлау: Канаш карьеры (карбонат токымнары), Әлкин карьеры (карбонат токымнары), Кәдек карьеры (карбонат токымнары). Карьерларны торгызу: Поповка карьеры (суглин), Чыбыклы карьеры ташлы ком чыгару буенча, Югары Шепкә карьеры (известьле токымнар), Югары Налим ком карьеры | | 1145,0 | 845,0 | 300,0 | | | | 5 | 2 | | | |
| 4 | Поповка авылында чишмәне төзекләндерү | | 300,0 | 300,0 | | | | | 1 | | | | |
| 5 | Кабан Бастрык авылында чишмәне төзекләндерү | | 300,0 | | 300,0 | | | | | 1 | | | |
| 6 | Сармашбаш авылында чишмәне төзекләндерү | | 300,0 | | 300,0 | | | | | 1 | | | |
| 7 | Гулькин авылында "Изге чишмә"не төзекләндерү | | 300,0 | | 300,0 | | | | | 1 | 1 | | |
| 8 | Куш Елга авылында чишмәне төзекләндерү | | 300,0 | | | 300,0 | | | | | 1 | | |
| 9 | Кара Елга авылында чишмәне төзекләндерү | | 400,0 | | | 400,0 | | | | | 1 | | |
| 10 | Урсай авылында чишмәне төзекләндерү | | 300,0 | | | 300,0 | | | | | 1 | | |
| 11 | Иске Маврин авылында чишмәне төзекләндерү | | 300,0 | | | | 300,0 | 300,0 | | | | 1 | |
| 12 | Ал. Бистәсе авылында чишмәне төзекләндерү | | 300,0 | | | | 300,0 | | | | | 1 | |
| 13 | Төги авылында чишмәне төзекләндерү | | 300,0 | | | | 300,0 | | | | | 1 | |
| 14 | Бөгелде елгасының үзәннәрен чистарту һәм ярларын ныгыту | | 470,0 | | 470,0 | | | | | 1 | | | |
| 15 | ГТСка капиталь ремонт буенча проект-смета документларын эшләү | | 990,0 | | 990,0 | | | | | 3 | | | 1 |
| 16 | ГТСны декларация алды тикшерүе | | 900,0 | | 300 | 200,0 | 400,0 | 95,0 | | 3 | 3 | 4 | |
| 19 | ГТС зыяны хисабы + иминиятләштерү | | 1060,0 | | | 600,0 | 400,0+60,0 | 100,0 | | | 3 | 8 | |
| 20 | Янгынга каршы чара буларак, буа ярларын ныгыту | | 200,0 | | | 100,0 | 100,0 | | | | 1 | 1 | |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | (Поповка, Яңа Налим) | | | | | | | | | | | |
| 21 | Кармалка елгасын чистарту һәм су саклау зонасы ярларын ныгыту. | Муниципаль бюджет | 1450,0 | 1000,0 | | | | 450 | 1 | | | |
| 22 | Яшел үсемлекләр сатып алу һәм утырту, агачларны санитар кисү. | | 9216,0,0 | 3116,0 | 2000,0 | 1800,0 | 800,0 | 700,0 | 600 | 400 | 400 | 500 | 750 |
| 24 | Агач-куаклар күчереп утырту өчен жайланма сатып алу. | | 1450,0 | 1450,0 | | | | | 1 | | | | 1 |
| 25 | Калдыкларны җыю, юк итү, утилләштерү, зарарсызландыру системасын оештыру (контейнер мәйданчыклары) | | 1450,0 | 630,0 | 670,0 | 150,0 | | | 15 | 18 | | | |
| 26 | Икенчел кулланылырга тиешле калдыкларны (батареялар өчен контейнерлар) аеру максатында калдыкларны селектив җыюны оештыру | | 100,0 | | | 100,0 | | | | | 10 | | |
| 27 | Җир көне, Экологик белемнәр көне, Урман көне уңаеннан экологик акцияләр, «Эзләнүләр һәм казанышлар» фәнни-гамәли конференциясе, «Чиста урман», «Сыерчык оясы» акцияләре оештыру. | | 100,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 6 | 6 | 6 | 6 | 6 |
| 28 | Экологик-мәгълүмати күрсәтмә материал әзерләү | | 82 | 30,0 | 16,3 | 26,8 | 8,8 | | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| 29 | “ЭкоЗәй”, “Чиста шәһәр – безнең эшебез”, “Йолдызлы җыештыру”, “Агач утырту”, “Яшьләр-чүп-чарга каршы”, “Ага чишмә челтер-челтер”, “оБЕРЕГай”, “Шәһәр елгаларына - чиста ярлар”, “Яшьтән табигать турында кайгыртып”, “Әйдәгез, кеше булып калыйк” экологик акцияләре уздыру | | 157,0 | 30,0 | 30,0 | 37,0 | 30,0 | 23,0 | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 |
| 30 | «Яшел дөнья синең кулларда» экология конференциясе, «Экодулкын» I шәһәр экологик яшьләр форумы | | 20,0 | 20,0 | | | | | 1 | | | | |
| 31 | ЭХБ (экология, химия, биология) лаборатор эшләр өчен класс комплекты.Төп мохитләр - һава, су һәм туфракны, шулай ук азык-төлек продуктларын экологик тикшерүдә укучыларның күрсәтмә тәҗрибәләрен мөстәкыйль уздыру – әлеге тирәлекләр турында заманча фәнни күзаллаулар тудыру. | | 111,0 | 111,0 | | | | | 1 | | | | |
| 32 | **Барысы:** | | **25670,4** | **7902,0** | **7427,8** | **4533,8** | **3418,8** | **2388,0** | | | | | |
| 33 | Предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар | Предприятиеләрнең үз акчалары | **100808** | **20303,8** | **20110,8** | **19979,8** | **20275,8** | **20137,8** | | | | | |
| 34 | **Барысы:** | | **126479** | **28205,8** | **27538,6** | **24513,6** | **23694,6** | **22526** | | | | | |